ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 март 2019ел № 1459

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле өстәмә кыйммәткә салым суммасы үзгәрү сәбәпле, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсе 1 бүлегенең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2018 елның 7 сентябрендәге 5011 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә, 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 22 мартындагы
1459 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, җиңел автомобильдә пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 404,80 |
| 2. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, җиңел автомобильдә пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 8,10 |
| 3. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, микроавтобуста (17 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 558,16 |
| 4. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, микроавтобуста (17 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 11,16 |
| 5. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, автобуста (43 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 1227,52 |
| 6. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, автобуста (43 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 24,55 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова